**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**МУНИЦИПАЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГАБИШЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422606 с. Габишево,
пр. Молодежный, д.1
тел: 4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ГАБИШЕВО**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-46-57

---

№7 2019 елның 16 апреленнән

# КАРАР

**“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишево авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы төстә тәкъдим ителүче хезмәтләр бәясен раслау турында**

2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, 1996 елның 12 гыйнварыннан №8-ФЗ “Җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварыннан №32 “2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында”гы карарына, 2004 елның 28 июленнән №45-ЗРТ “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы ТР Законына, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2007 елның 18 маеннан №196 “Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында”гы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча чаралар турында”гы карарына, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишево авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы төстә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишево авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы төстә тәкъдим ителүче хезмәтләр бәясен 1нче һәм 2нче кушымталарга ярашлы төстә 2019 елның 1 февраленнән 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Габишево авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Т.Хөсәенов**